**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КУЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422612, РТ, Лаишевский район,
с.Курманаково, ул.Центральная, д.26-а
тел:89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422612, РТ, Лаеш район, Курманаково
авылы, Центральная ур, 26-а йорт
тел: 89061111775, kuuk.la@tatar.ru

**2024лның 11 ноябре** **49 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлеге составына керүче Курманак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 9 ноябрендәге «2025 елда үзара салым кертүгә Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегенең Курманак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидларны исәпкә алмыйча, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны-

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

-сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 75 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40 кеше.

Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегендә яшәүчеләрдән җыелу суммасын 500 сумнан 3000 сумга арттыру тәкъдиме чыкты. Әлеге тәкъдимне тавыш бирүгә чыгардылар.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында 40 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Көек авыл җирлегенең Курманак торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең Курманак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025

елда үзара салым акчаларын 3000 сум күләмендә кертергә. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазлар тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү буенча эшләр өчен түләүгә юллау белән килешәсезме дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Көек авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Көек авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________________ Л.М.Сатдинова
(имза) (имза расшифровкасы)

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Көек
авыл җирлеге Советы рәисе: __________________ Л.М.Сатдинова
(имза)(имза расшифровкасы)